ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге составына керүче Уразбахты авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 2 «24» октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында 2024 елның «24» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, махсус хәрби операциядә мобилизацияләнгән катнашучылар һәм аларнын гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 нче елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Уразбахтино торак пунктында урамнарны яктырту лампаларын агымдагы ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Уразбахты торак пунктында чокырларны ремонтлау); Уразбахтино торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Уразбахтино торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру 2 шт).

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 165 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 93 кеше, 56 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен 93 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен _ 0 _ кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: " Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, махсус хәрби операциядә мобилизацияләнгән катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 нче елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Уразбахтино торак пунктында урамнарны яктырту лампаларын агымдагы ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Уразбахты торак пунктында чокырларны ремонтлау); Уразбахтино торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Уразбахтино торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру 2 шт).

3. Әлеге карарны Уразбахты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Шәйхетдинов